**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**АКСУБАЙ МУНИИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 6 23.09.2015ел.

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесен
билəүгə конкурс игълан итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясы, Аксубай муниципаль районы Уставының статьясы, шулай ук Башкарма комитет Җитәкчесе вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә Аксубай муниципаль районы Советы, Аксубай муниципаль районы Советы вәкаләтләре срогы чыкканга күрә, Аксубай муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынына конкурс игълан итәргә.

Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъвачылардан конкурска документлар кабул итүне 25.09.2015-15.10.2015 елларда түбәндәге адрес буенча башкарырга кирәк: ТР, Аксубай районы, пгт. Аксубай, Ленин ур., 8.

2. Конкурс комиссиясе 16.10.2015 елны 10.00 сәгатьтә Аксубай муниципаль районы Советы бинасында ТР, Аксубай районы,пгт. Аксубай, Ленин ур., 8 й.Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә Аксубай муниципаль районы Советының 11.11.2005 елдагы 7 номерлы карары белән расланган (Аксубай муниципаль район Советының 16.10.2010 елдагы 4 нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) һәм конкурс нәтиҗәләрен һәм Аксубай муниципаль район Советына кандидатлар турындагы мәгълүматны тапшырырга.

3. Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә 6 кешедән торган кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясенең санлы составын расларга.

4. 1 нче кушымта нигезендә Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссиясе составының яртысын расларга.

5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы

Советының Җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К. К. Гилманов

Аксубай
муниципаль район Советының
№ 6 от 23.09.2015г.карарына
1 нче кушымта

**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫННАН АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ ВАЗЫЙФАСЫН БИЛӘҮГӘ КАНДИДАТУРАЛАРНЫ КАРАУ ӨЧЕН КОНКУРС КОМИССИЯСЕНЕҢ ЯРТЫ СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Баширова Рузиля Равильевна | **Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Аксубай муниципаль районы буенча җәмәгать ярдәмчесе** |
| 2 | Бобкова Галина Павловна | **Аксубай муниципаль районы Ветераннар советы рәисе** |
| 3 | Киселева Галина Семеновна | **Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогы депутаты** |